РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 19 » 06 2023 г. №893

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында туберкулез, ВИЧ-инфекциягә каршы көрәш буенча ведомствоара комиссия турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, “Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында” 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы Федераль закон, “Россия Федерациясендә туберкулез таралуны кисәтү турында” 2001 елның 18 июнендәге 77-ФЗ номерлы Федераль закон, “Кеше иммунодефициты вирусы (ВИЧ-инфекция) китереп чыгара торган авыру таралуны кисәтү турында” 1995 елның 30 мартындагы 38-ФЗ номерлы Федераль закон, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, “Ютазы муниципаль районы муниципаль берәмлеге” Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы халкы арасында туберкулез, ВИЧ-инфекция, башка социаль әһәмияткә ия авыруларны профилактикалау, иртә ачыклау һәм аларның үсешен киметү буенча кичектергесез чаралар күрү максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты
карар бирә:

1. Расларга:
- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында туберкулезга, ВИЧ-инфекциягә каршы көрәш буенча ведомствоара комиссия составын (1 нче кушымта);
- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында туберкулезга, ВИЧ-инфекциягә каршы көрәш буенча ведомствоара комиссия турында Нигезләмәне (2 нче кушымта);
- 2023-2027 елларга Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында туберкулезга каршы көрәш буенча ведомствоара комиссия эше планын (3 нче кушымта).

2. «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында туберкулез, ВИЧ-инфекция белән көрәш буенча ведомствоара комиссия турында» Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 07 сентябрендәге 703 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталы составында http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга .

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина

С.А. Рузанов
тел. 2-42-05

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитетының
«____»_________20 __ел №_______
карарына №2 кушымта

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында туберкулезга, ВИЧ-инфекциягә каршы көрәш буенча ведомствоара комиссия составы

| | |
|---|---|
| Самонина С. П. | Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе; |
| Дружков И.Г. | Татарстан Республикасы буенча Россия кулланучылар күзәтчелеге идарәсенең Бөгелмә, Азнакай, Баулы, Ютазы районнарында территориаль бүлеге начальнигы урынбасары, комиссия рәисе урынбасары (килешү буенча); |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Абдурахманов Р.Р. | «Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге» МКУ начальнигы; |
| Галләмова Р. А. | Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының «Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге» МКУ начальнигы; |
| Шакирова С.З. | «Урыссу үзәк район хастаханәсе» ДАССУ баш табибы (килешү буенча); |
| Л.Ф. Сәлимгәрәев | Россия Эчке эшләр министрлыгының Ютазы районы буенча бүлеге начальнигы |
| Абрамов С.А. | «Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ начальнигы; |

Дәүләтбаева Ю.Р. «Татмедиа» АҖ филиалының директоры «Ютазы таны» («Ютазинская новь») район газетасының баш мөхәррире (килешү буенча);

-

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитетының
«____»_________20 __ел №_______
карарына №2 кушымта

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында туберкулезга, ВИЧ-инфекциягә каршы көрәш буенча ведомствоара комиссия турында Нигезләмә

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында туберкулезга, ВИЧ-инфекциягә каршы көрәш буенча ведомствоара комиссия (алга таба - комиссия) туберкулезга, ВИЧ-инфекциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча сәламәтлек саклау учреждениесе эшен координацияләү, туберкулез, ВИЧ-инфекция авыруларын профилактикалауга һәм кисәтүгә юнәлдерелгән бурычларны хәл итү, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә санитар-эпидемиологик иминлекне тәэмин итү өчен булдырылган даими киңәш органы булып тора.

2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының гамәлдәге законнарына, муниципаль хокукый актларга, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

3. Комиссиянең төп бурычлары түбәндәгеләр:

- туберкулез, ВИЧ-инфекция кебек массакүләм авыруларны профилактикалау һәм халыкның санитар-эпидемиологик иминлеген тәэмин итү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру чараларын эшләүдә катнашу һәм бердәм стратегия формалаштыру;

- туберкулезны, ВИЧ-инфекцияне профилактикалау буенча төп социаль, медицина, икътисадый һәм башка проблемаларны комплекслы һәрьяклап өйрәнү;

- туберкулезга, ВИЧ-инфекциягә каршы көрәш, халыкның санитар-эпидемиологик иминлеген тәэмин итү буенча максатчан программалар эшләүдә катнашу;

- Россия Федерациясе санитария законнарын бозу нәтиҗәсендә гражданнарның сәламәтлегенә зыян салу мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр эшләүдә катнашу.

4. Комиссия үзенә йөкләнгән бурычлар нигезендә түбәндәге функцияләрне үтәүне гамәлгә ашыра:

- Татарстан Республикасының Ютазы муниципаль районы территориясендә халыкның санитар-эпидемиологик иминсезлеге барлыкка килүенә бәйле мәсьәләләрне оператив хәл итүне оештыру;

- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә санитар-эпидемиологик торышны анализлау, аның үзгәрүен фаразлау һәм Россия Федерациясе санитария законнарын үтәү буенча тәкъдимнәр;

- массакүләм мәгълүмат чаралары аша комиссия эшчәнлегенең юнәлешләре һәм нәтиҗәләре турында халыкка мәгълүмат җиткерү.

5. Комиссия түбәндәгеләргә хокуклы:

- туберкулез, ВИЧ-инфекция таралуны кисәтү чараларын гамәлгә ашыру буенча предприятиеләр, оешмалар, учреждениеләр җитәкчеләреннән, аларның нинди ведомствога каравына һәм оештыру-хокукый формасына бәйсез рәвештә, кирәкле материаллар соратырга;

- үз утырышларында җирле үзидарә органнары вазыйфаи затларын, предприятие, учреждение һәм оешма җитәкчеләрен, аларның нинди ведомствога каравына һәм оештыру-хокукый формасына карамастан, туберкулез, ВИЧ-инфекция авыруларын профилактикалауга һәм халыкның санитар-эпидемиологик иминлеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашырулары турында тыңларга;

- җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затларына, предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар җитәкчеләренә туберкулез, ВИЧ-инфекция белән авыручылар саны турында, аларның үзгәрешләрен фаразлау, профилактика чаралары, аларга каршы көрәш чаралары комплексы турында мәгълүмат бирергә;

- алар гаебе белән туберкулез белән авыру очракларына юл куелган яки ВИЧ-инфекция таратуда гаепле булган вазыйфаи затларны һәм гражданнарны җаваплылыкка тарту мәсьәләсен хәл итү өчен тиешле органнарга мәгълүмат бирергә.

6. Комиссиянең эш тәртибе.

6.1. Комиссия вәкиллекле нигездә төзелә. Комиссия составына җирле үзидарә органнары вәкилләре, шулай ук башка органнар һәм оешмалар, иҗтимагый берләшмәләр вәкилләре, галимнәр, белгечләр һәм җәмәгать эшлеклеләре кушыла. Комиссия әгъзалары җәмәгать башлангычларында үз эшчәнлекләрен гамәлгә ашыралар һәм аның утырышларында шәхсән катнашалар. Комиссия утырышларына прокуратура, суд, эшкуарлык структуралары, иҗтимагый оешмалар вәкилләре чакырылырга мөмкин. Комиссия утырышлары кварталга кимендә 1 тапкыр уздырыла.

6.2. Комиссия үз эшчәнлеген комиссия рәисе раслый торган эш планы нигезендә гамәлгә ашыра. Комиссия утырышларын комиссия рәисе, ул булмаганда, комиссия рәисе урынбасары үткәрә.

6.3. Комиссия утырышы, әгәр анда комиссия составының яртысыннан артыгы катнашса, тулы хокуклы. Комиссиянең барлык карарлары комиссия әгъзаларының гомуми составының күпчелек тавышы белән кабул ителә.

6.4. Комиссия карарлары аның утырышлары беркетмәләре рәвешендә рәсмиләштерелә, алар утырышта рәислек итүче тарафыннан раслана һәм комиссия секретаре тарафыннан имзалана. Карарлар кызыксынган предприятиеләр,

учреждениеләр, оешмалар җитәкчеләренә, ведомствосы нинди булуга һәм оештыру-хокукый рәвешенә карамастан, тиешле өземтә рәвешендә җиткерелә. Комиссия карарлары рекомендация характерында була.

7. Комиссия эшчәнлеген оештыру-техник тәэмин итү «Урыссу үзәк район хастаханәсе» ДАССУ тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитетының
«__»_______ 20 __ел №____
карарына №3 кушымта

2023-2027 елларга Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында туберкулезга каршы көрәш буенча ведомствоара комиссия эше планы

| № т/б | Чараның исеме | Үтәү срогы | Җаваплы башкаручы |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Оештыру-методик чаралар | | |
| 1.1. | Ютазы районы территориясендә ВИЧ-инфекция, туберкулез таралуга каршы көрәш буенча ведомствоара комиссиянең системалы эшен тәэмин итү (алга таба - ведомствоара комиссия) | 2023 - 2027 еллар | Ведомствоара комиссия, ТР буенча Роспотребнадзор идарәсенең Бөгелмә, Азнакай, Баулы, Ютазы районнарында территориаль бүлеге |
| 1.2. | Ведомствоара комиссия утырышларында территориаль органнар, федераль башкарма хакимият органнары, Ютазы муниципаль районы башкарма комитеты органнары вәкилләренең ВИЧ-инфекция, туберкулез таралуын булдырмауга юнәлдерелгән чараларны | 2023 - 2027 еллар | Ведомствоара комиссия, ТР буенча Роспотребнадзор идарәсенең Бөгелмә, Азнакай, Баулы, Ютазы районнарында территориаль бүлеге |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | оештыру һәм гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча тыңлауларны оештыру | | |
| 1.3. | Халык арасында ВИЧ-инфекцияне, туберкулезны профилактикалау һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре буенча мәгълүмати-агарту эшен массакүләм мәгълүмат чараларын җәлеп итеп үткәрүне оештыру | 2023 - 2027 еллар | “Урыссу үзәк район хастаханәсе” ДАССУ, ТР буенча Роспотребнадзор идарәсенең Бөгелмә, Азнакай, Баулы, Ютазы районнарында территориаль бүлеге |
| 1.4. | Бөтендөнья СПИД корбаннарын искә алу көненә һәм Бөтендөнья СПИД белән көрәшү көненә багышланган, массакүләм мәгълүмат чараларын, иҗтимагый, дини оешмаларны җәлеп итеп, тематик акцияләр һәм башка чаралар оештыру һәм үткәрү | 1 декабрь | Ведомствоара комиссия әгъзалары |
| 1.5. | Ютазы районы халкына массакүләм мәгълүмат чаралары, иҗтимагый, дини оешмалар катнашында мөһим даталарга багышланган массакүләм чаралар уздырганда ВИЧ-инфекцияне, туберкулезны профилактикалау мәсьәләләре буенча мәгълүмат бирүне оештыру | 2023 - 2027 еллар | Ведомствоара комиссия әгъзалары |
| 1.6. | Социаль партнерлыкны үстерү һәм ВИЧ-инфекция буенча профилактик | 2023 - 2027 еллар | Ведомствоара комиссия әгъзалары |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | эшләрдә катнашу өчен район халкы, шул исәптән бирешүчән төркемнәр һәм социаль яктан яраклашмаган категорияләр катнашып, иҗтимагый, сәяси һәм дини оешмалар өчен массакүләм мәгълүмат чараларын җәлеп итеп "түгәрәк өстәлләр", брифинглар, конференцияләр, семинарлар үткәрүне оештыру | | |
| 1.7. | Медицина оешмаларының, мәгариф оешмаларының, социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының, шулай ук Ютазы районы территориясендә урнашкан башка оешмаларның ВИЧ-инфекцияне профилактикалау буенча мәгълүмати-методик материаллар белән тәэмин итүне оештыру | 2023 - 2027 еллар | "Урыссу үзәк район хастаханәсе" ДАССУ |
| 1.8. | ВИЧ-инфекциясен профилактикалау һәм сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау чараларын үткәрүгә мәдәният, мәгариф, спорт оешмаларын җәлеп итүне оештыру | 2023 - 2027 еллар | Ведомствоара комиссия әгъзалары |
| 2. | Укучы яшьләр арасында ВИЧ-инфекция таралуны һәм профилактикалауны булдырмау чаралары | | |
| 2.1. | Белем бирүче мәгариф оешмалары һәм аларның | 2023 - 2027 | «Урыссу үзәк район хастаханәсе» ДАССУ, «Ютазы |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | ата-аналары арасында, методик һәм күрсәтмә материалларны файдаланып, ВИЧ-инфекцияне профилактикалау мәсьәләләре буенча мәгълүмати-агарту эшен (лекцияләр, әңгәмәләр, конкурслар, тренинглар) оештыру һәм үткәрү | еллар | муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге" МКУ; |
| 2.2. | ВИЧ-инфекцияне, туберкулезны профилактикалау мәсьәләләре буенча район мәдәният, мәгариф, спорт һәм яшьләр сәясәте бүлекләре хезмәткәрләренә мәгълүмат бирүне оештыру | 2023 - 2027 еллар | Ведомствоара комиссия әгъзалары |
| 2.3. | Ютазы муниципаль районының чакырылыш комиссияләре базасында хәрби хезмәткә чакырылу алдындагылар арасында ВИЧ-инфекцияне профилактикалау һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру буенча мәгълүмат-агарту эшен оештыру һәм үткәрү | 2023 - 2027 еллар | "Урыссу үзәк район хастаханәсе" ДАССУ |
| 3. | Ютазы районы хезмәт коллективларында ВИЧ-инфекция таралуны булдырмау һәм профилактикалау чаралары | | |
| 3.1. | Эш урыннарында ВИЧ-инфекцияне профилактикалау мәсьәләләре буенча Ютазы районы эш белән тәэмин | 2023 - 2027 еллар | Ведомствоара комиссия әгъзалары |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | итүчеләре өчен семинарлар, "түгәрәк өстәлләр", киңәшмәләр оештыру һәм уздыру | | |
| 3.2. | Ютазы районы хезмәт коллективларына, методик киңәшләр һәм күрсәтмә материаллар кулланып, ВИЧ-инфекцияне профилактикалау чараларын үткәрүдә консультация һәм методик ярдәм күрсәтүне оештыру | 2023 - 2027 еллар | Ведомствоара комиссия әгъзалары |
| 4. | Медицина оешмаларында ВИЧ-инфекция таралуын булдырмау һәм профилактикалау чаралары | | |
| 4.1. | Медицина ярдәме күрсәткәндә медицина оешмаларының медицина хезмәткәрләре белән бергә ВИЧ-инфекцияне профилактикалау мәсьәләләре буенча семинарлар, конференцияләр уздыруны оештыру | 2023 - 2027 еллар | "Урыссу үзәк район хастаханәсе" ДАССУ |
| 4.2. | Медицина оешмаларын кирәкле күләмдә медицина билгеләнешендәге әйберләр ( кирәк булганда, бер тапкыр кулланыла торган) һәм инструментларны (җиһазларны) эшкәртү һәм аларны пациентларда куллану арасында вакыт аралыгын саклауны тәэмин итүче җиһазлар белән | 2023 - 2027 еллар | ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | җиһазландыруны оештыру | | |